| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

19.12.2018 № 1046

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының торак сәясәте бүлеге тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең технологик схемаларын раслау турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законны гамәлгә ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында» 2010 ел, 2 ноябрь, 880 нче карарына таянып

КАРАР БИРӘМ:

1. Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының торак сәясәте бүлеге тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең технологик схемасын расларга:

1.1. «2014-2020 елларга Татарстан Республикасында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» ярдәмче программасы буенча торак сатып алуга (төзүгә) социаль түләү алуга хокук турында таныклык бирү һәм исәпкә кую буенча муниципаль хезмәте күрсәтүнең технологик схемасы (1 нче кушымта);

1.2. «Татарстан Республикасында социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗлар исәбенә кую» муниципаль хезмәте күрсәтүнең технологик схемасы (2 нче кушымта);

1.3. «Торак урыннарына мохтаҗ гражданнарның аерым категорияләрен исәпкә кую» муниципаль хезмәте күрсәтүнең технологик схемасы (3 нче кушымта);

1.4. «Чернобыль АЭСындагы һәлакәт, “Маяк” җитештерү берләшмәсендәге авария аркасында радиация йогынтысына дучар ителгән гражданнарга һәм аларга тиңләштерелгән затларга Дәүләт торак сертификатын бирү һәм исәпкә кую» муниципаль хезмәте күрсәтүнең технологик схемасы (4 нче кушымта);

1.5. «Торак шартларын яхшыртуга мохтаҗлар буларак исәпкә кую һәм мәҗбүри күченүчеләргә торак сатып алуга субсидияләр бирү өчен Дәүләт торак

сертификаты бирү» муниципаль хезмәте күрсәтүнең технологик схемасы (5 нче кушымта);

1.6. «Муниципаль торак фондыннан гражданга социаль наем шартнамәсе буенча торак урыны бирү» муниципаль хезмәте күрсәтүнең технологик схемасы (6 нчы кушымта);

1.7. «Социаль түләүләр кулланып торак шартларын яхшыртырга һәм авыл җирлегендә торак төзүгә (сатып алуга) социаль түләү турында таныклык алырга теләк белдергән гражданнар исемлегенә кертү» муниципаль хезмәте күрсәтүнең технологик схемасы (7 нче кушымта);

1.8. «Муниципаль торак фондында гражданнарга хезмәт торак урыны наймы шартнамәләре буенча торак урыннары бирү» муниципаль хезмәте күрсәтүнең технологик схемасы (8 нче кушымта);

1.9 «Социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннары бирүгә мохтаҗ гражданнарны исәпкә алу» муниципаль хезмәте күрсәтүнең технологик схемасы (9 нчы кушымта).

2. Әлеге карар үз көченә кергәннән бирле «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының торак сәясәте бүлеге тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең технологик схемаларын раслау турында» 2018 елның 11 маендагы 344 номерлы карары үз көчен югалткан дип санарга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче Л.Н. Маняпов